Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чытырчы авыл җирлеге Советы

Карар

2025 елның 14 ноябре № 3/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чытырчы авыл җирлеге Советының «Җир салымын гамәлгә кертү, ставкаларны, түләү тәртибен билгеләү турында» 2016 елның 10 ноябрендәге 23/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чытырчы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чытырчы авыл җирлеге Советының «Җир салымын гамәлгә кертү, ставкаларны, түләү тәртибен билгеләү турында» 2016 елның 10 ноябрендәге 23/1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле яңа 4.1 пункт өстәргә:

«Салымны һәм салым буенча аванс түләүләрен түләү тәртибе: салымны һәм салым буенча аванс түләүләрен салым түләүче-оешмалар Россия Федерациясе Салым кодексының 397 статьясы нигезендә түләргә тиеш.».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм (яисә) «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы М.В. Новиков